**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**

**2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Мордва Каратай авылында үзара салым кертү турында**

**2022 елның 25 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Мордва Каратай авыл җирлегендә гражданнар җыены карар итте:

1.2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Мордва Каратай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1700,00 (бер мең җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- бистә эчендәге һәм межуличара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (вак таш, ком һәм грунт сатып алу, ташу, салу, грейдирование, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- юлларны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- территорияне төзекләндерү, шул исәптән язгы-көзге чорда чүп үләннәрен чабу (трап ясау өчен төзелеш материалларын сатып алу, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Мордва Каратай авылы, Үзәк йорт 7, авыл клубы бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Кирельский авыл җирлеге башлыгы

Кама Тамагы муниципаль районы

Татарстан Республикасы районнары: Ф.Я.Зиннәтуллин